**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 183-32 «28» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 111-19 номерлы «Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 111-19 номерлы «Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзацны өстәргә:

«- җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча, Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән вакыт узганнан соң, 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Маяк»район газетасында мәгълүмати хәбәрне бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин